| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

13.12.2019 № 1081

«2020-2022 елларга Нурлат муниципаль районында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту» муниципаль максатчан программасын раслау турында

Россия Федерациясенең 2001 елның 30 декабрендәге 197-ФЗ номерлы Хезмәт кодексы, «Хезмәтне саклау буенча дәүләт норматив таләпләрен үз эченә алган норматив хокукый актларны эшләү, раслау һәм үзгәртү турындагы нигезләмәне раслау турында» 2010 елның 27 декабрендәге 110 номерлы РФ Хөкүмәте карары, «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» 1997 елның 10 декабрендәге 1417 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

КАРАР ИТТЕ:

1. «2020-2022 елларга Нурлат муниципаль районында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту» муниципаль максатчан программасын (алга таба - Программа) расларга (1 нче кушымта).
2. Предприятие, оешма җитәкчеләренә һәм дәүләт күзәтчелеге органнарына хезмәтне саклау чараларын эшләгәндә, милекнең оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә, әлеге программага таянып эш итәргә тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Л.Н.Маняпов

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 13 декабрендәге 1081 номерлы карарына кушымта

# «2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту» муниципаль максатчан программасы

**«2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту»**
**муниципаль максатчан программасы паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту» муниципаль программасы (алга таба-Программа) |
| Программа эшләү өчен нигез | Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» 1997 елның 10 декабрендәге 1417 номерлы Татарстан Республикасы Законы (2014 елның 23 июлендәге 60-ТРЗ номерлы үзгәрешләр белән) |
| Программаның төп эшләүчеләре | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты, хезмәтне саклау буенча координация советы, эш бирүчеләр, предприятие, учреждениеләр, район оешмалары профсоюзлары комитетлары |
| Программаның заказчысы | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның максаты | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан оешмалар хезмәткәрләренең җитештерү травматизмын һәм һөнәри авырулар белән авыруын киметү максатларында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту |
| Программаның бурычлары | 1. Хезмәтне саклау өлкәсендә норматив-хокукый базаны камилләштерү.<br>2. Хезмәтне саклау буенча укуларны оештыру.<br>3. Мәгълүмати тәэмин итү һәм хезмәтне саклауны пропагандалау.<br>4. Эшче халыкка дәвалау-профилактика хезмәтен күрсәтүне камилләштерү.<br>5. Хезмәт шартлары һәм аны саклау мониторингы үткәрү.<br>6. Эш урыннарында хезмәт шартларын махсус бәяләү үткәрү һәм аларны хезмәтне саклау норматив таләпләренә туры китерү. |
| Программаны гамәлгә кую сроклары | 2020-2022 еллар |
| Программаны финанслауның күләме һәм чыганаклары | Предприятие һәм оешма чыганаклары. |
| Индикаторы (показатели) муниципальной программы | 1нче бурычның индикаторлары (күрсәткечләре):<br>- башкарыла торган эшләр төрләре һәм һөнәрләр буенча хезмәтне саклау буенча инструкцияләр эшләү, оешмаларда хезмәтне саклау эшен оештыру буенча нигезләмәләр эшләү, оешмалар эшчәнлеге үзенчәлекләренә туры китереп хезмәтне саклау таләпләрен үз эченә алган норматив хокукый актлар комплектын формалаштыру;<br>- хезмәтне саклау белән идарә итүнең заманча системасын гамәлгә кертү.<br>2нче бурычның индикаторлары (күрсәткечләре):<br>- муниципаль программа буенча укырга планлаштырылган хезмәткәрләрнең гомуми санынннан хезмәтне саклау буенча укытылган хезмәткәрләрнең чагыштырма өлеше.<br>3нче бурычның индикаторлары (күрсәткечләре): |

| | |
|---|---|
| | Район массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Нурлат муниципаль районы сайтында хезмәтне саклау проблемалары буенча бастырылган материаллар саны;<br>- хезмәтне саклау мәсьәләләрен карап тикшерү белән үткәрелгән семинарлар һәм киңәшмәләр саны.<br>4нче бурычның индикаторлары (күрсәткечләре):<br>- муниципаль программа белән планлаштырылган периодик медицина тикшерүләрен узган хезмәткәрләрнең чагыштырма өлеше.<br>5нче бурычның индикаторлары (күрсәткечләре):<br>-район хакимиятенә хезмәтне саклау мәсьәләләре буенча квартал саен мәгълүмат бирүче оешмаларның Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан оешмаларның гомуми санына карата чагыштырма өлеше.<br>6нчы бурычның индикаторлары (күрсәткечләре):<br>Нурлат муниципаль районы оешмаларында эш урыннарының гомуми саныннан хезмәт шартларын махсус бәяләү үткәрелгән эш урыннарының чагыштырма өлеше |
| Муниципаль программаны тормышка ашыру барышын тикшереп торуны оештыру системасы | Муниципаль программаны тормышка ашыруның барышын Нурлат муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы рәисе контрольдә тота. |

# 1. Хезмәтне саклау программасын гамәлгә ашыру өлкәсенең характеристикасы, төп проблемалары

Хәзерге икътисади шартларда җәмгыятьнең социаль-икътисади иминлегенә эш урыннарында сәламәт һәм куркынычсыз хезмәт шартлары тудыру зур йогынты ясый.

Программа яңа икътисади һәм хезмәт мөнәсәбәтләренә туры килә торган хезмәтне саклау белән дәүләт идарәсе системасын алга таба камилләштерүгә, хезмәт эшчәнлеге барышында хезмәткәрләрнең гомерен һәм сәламәтлеген саклау таләпләренә җавап бирә торган хезмәт шартларын тәэмин итүгә, дәүләт гарантияләрен һәм хезмәтне саклау һәм эшчеләрне хокукый яклауга, производствода имгәнүләрне һәм һөнәри авыруларны кисәтүгә һәм профилактикалауга юнәлдерелгән.

Нурлат муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы күп кенә оешмаларда хезмәт шартлары һәм аны саклауның торышы катлаулы булып кала һәм җитди социаль-икътисади проблема булып тора.

Хезмәткәрләрнең хезмәт куркынычсызлыгы, аларның тормышы һәм сәламәтлеге турыдан-туры хезмәтне саклауга бүлеп бирелә торган суммадан тора. Хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау чараларын финанслау эш бирүченең Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 226 нчы маддәсе нигезендә бурычы булып тора.

Эш урыннарында һөнәри хәвеф-хәтәрләрне киметү максатларында, хезмәтне саклау өлкәсендә эшчеләрне максатчан укыту һәм һөнәри әзерләү мөһим роль уйный. Районда бу мәсьәләгә аеруча зур игътибар бирелә, чөнки хезмәтне саклау өлкәсендә эш бирүчеләрнең иң зур хокук бозулары хезмәтне саклау буенча хезмәткәрләрне укыту һәм инструкцияләү мәсьәләләренә бәйле.

Җитештерүдәге имгәнүләрнең сәбәпләрен анализлап, шуны әйтергә кирәк, соңгы еллар дәвамында алар үз холкы буенча үзгәрмәде. Төп сәбәпләре булып түбәндәгеләр тора:

- хезмәт һәм җитештерү дисциплинасын бозу;
- куркынычсыз хезмәт шартларына укытуда җитешсезлекләр.

Нурлат муниципаль районында хезмәтне саклау буенча координацион совет төзелде һәм эшлщп килә. Хезмәтне саклау буенча координация советы утырышларында эшләрне башкарганда хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык техникасы таләпләрен үтәү, хезмәтне саклау буенча белгечләрнең квалификациясен күтәрү, предприятиеләрдә хезмәтне саклау буенча белемнәрне тикшерү, хезмәткәрләргә алдан һәм периодик тикшерүләр үткәрү, оешма хезмәткәрләре белән даими инструктажлар үткәрү, даими медицина тикшерүе узу мәсьәләләре карала, Нурлат районында балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру һәм җәйге ял вакытында яшүсмерләр арасында производствода имгәнүләрне кисәтү, җитештерүдәге бәхетсезлек очракларын киметү, профилактикада бәхетсезлек очракларын кисәтү, төзелеш объектларында куркынычсыз хезмәт шартларын тәэмин итү, терроризмга каршы тору режимын көчәйтү, хезмәт шартларын махсус бәяләү, хезмәтне саклау турындагы законнарны үтәү мәсьәләләре карала. Нурлат муниципаль районы оешмаларында хезмәтне саклау өлкәсендә ирешелгән уңай нәтиҗәләр бар, әмма вәзгыять шактый киеренке булып кала.

Нурлат районында эшкә сәләтле халыкның тормыш сыйфатын күтәрү һәм сәламәтлеген саклау өлешендә программаны эшләү һәм гамәлгә ашыру кирәклеген билгеләүче мөһим фактор булып әлеге проблеманың социаль әһәмияте тора.

## 2. Программаның максаты һәм бурычлары.

Муниципаль программаның максаты булып:

- Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан оешмалар хезмәткәрләренең һөнәри авыруын һәм җитештерү травматизмын киметү максатларында хезмәт шартларын һәм аларны саклауны яхшырту тора.

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

- хезмәтне саклау өлкәсендә норматив-хокукый базаны камилләштерү;
- хезмәтне саклау буенча укуларны оештыру;
- мәгълүмати тәэмин итү һәм хезмәтне саклауны пропагандалау;

- эшче халыкка дәвалау-профилактика хезмәтен күрсәтүне камилләштерү;
- хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау мониторингы үткәрү.
- эш урыннарында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны махсус бәяләү уздыру һәм аларны хезмәтне саклау норматив таләпләренә туры китерү.

## 3. Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре

Муниципаль программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә түбәндәге чаралар көтелә: хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау, уңайсыз хезмәт шартларында мәшгуль хезмәткәрләр саны кимү;

- җитештерүдәге җәрәхәтләнүләрне профилактикалау буенча чаралар үткәрүгә эш бирүчеләрнең игътибарын юнәлдерү;
- хезмәтне саклауны пропагандалау һәм мәгълүмат белән тәэмин итүне яхшырту.

Муниципаль программаның индикаторлары (күрсәткечләре) булып түбәндәгеләр тора:

- производствода бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә зыян күргән 1000 эшчегә исәпләгәндә 1 эш көненә һәм аннан да озакракка эшкә яраклылыгын югалткан кешеләр саны;
- 1000 эшчегә исәпләгәндә, производствода бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә зыян күргән үлем белән тәмамланган кешеләр саны;
- җитештерүдә бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә зыян күргән кешеләрнең эшкә яраклылыгы 1 эш көненә һәм аннан да күбрәк булган эшкә яраксызлыгы көннәре саны.

Әлеге күрсәткечләр динамикасы алдагы программаның үтәлгән чараларының нәтиҗәлелеге турында сөйли.

Индикаторлар (күрсәткечләр):

1нче бурыч: район хакимиятенә хезмәтне саклау мәсьәләләре буенча квартал саен мәгълүмат бирүче оешмаларның Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан оешмаларның гомуми санына карата чагыштырма өлеше.

2нче бурыч: башкарылган эшләр төрләре һәм һөнәрләр буенча хезмәтне саклау буенча эшләнгән инструкцияләр саны, хезмәтне саклау буенча норматив хокукый актлар комплектларын формалаштыру;

3нче бурыч:

- хезмәткәрләрнең гомуми саныннан хезмәтне саклау буенча муниципаль программа буенча укырга планлаштырылган хезмәткәрләрнең чагыштырма өлеше;

4нче бурыч:

Нурлат муниципаль районы сайтында һәм район матбугатында хезмәтне саклау проблемалары буенча бастырылган материаллар саны;

хезмәтне саклау мәсьәләләрен карап тикшерү белән үткәрелгән семинарлар һәм киңәшмәләр саны.

5нче бурыч:

- муниципаль программа белән планлаштырылган вакытлы медицина тикшерүләрен узган хезмәткәрләрнең чагыштырма өлеше.

6нчы бурыч:

- Нурлат муниципаль районы оешмаларында эш урыннарының гомуми саныннан хезмәт шартларын махсус бәяләү үткәрелгән эш урыннарының чагыштырма өлеше.

## 4. Программа чаралары исемлеге

Муниципаль программа чаралары системасы Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан оешмаларда хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау торышын анализлау, статистик мәгълүмат һәм эш бирүчеләрдән, профсоюзлардан кергән тәкъдимнәр нигезендә билгеләнгән.

Муниципаль программада түбәндәге чаралар каралган: хезмәтне саклау өлкәсендә норматив-хокукый базаны камилләштерү; хезмәткәрләрне хезмәтне саклау буенча укытуны оештыру; хезмәтне саклауны мәгълүмат белән тәэмин итү һәм пропагандалау; хезмәткәрләрне периодик медицина тикшерүләре үткәрүне оештыру; Нурлат муниципаль районы оешмаларында хезмәт шартларына һәм

хезмәтне саклауга мониторинг үткәрү; эш урыннарында хезмәт шартларын махсус бәяләү үткәрү һәм оешмаларда куркыныч җитештерү факторларына махсус бәяләү үткәрү.

## 5. Программаны тормышка ашыру белән идарә итү механизмы

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль программаны гамәлгә ашыруның барышына гомуми җитәкчелек, контрольлек итә.
Муниципаль программа белән агымдагы идарә итүне Татарстан Республикасының Нурлат муниципаль районында хезмәтне саклау буенча координация советы гамәлгә ашыра.

## Программа чаралары исемлеге

| Чаралар атамасы | Тормышка ашыру сроклары | Финанслау чыганаклары | Башкаручылар |
|---|---|---|---|
| Нурлат муниципаль районында хезмәтне саклау буенча Координацион совет составына өстәмәләр һәм үзгәрешләр әзерләү һәм кабул итү. | 2020-2022 | Таләп ителми | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты, Нурлат муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы, оешма җитәкчеләре |
| «2020-2022 елларга Нурлат муниципаль районында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту» муниципаль программасын әзерләү һәм кабул итү | 2022 | Таләп ителми | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты, Нурлат муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы |
| Нурлат муниципаль районы оешмаларында эш төрләре һәм һөнәрләр буенча хезмәтне саклау буенча инструкцияләр эшләү. | 2020-2022 | Эш бирүчеләр акчасы | Нурлат муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы, оешма җитәкчеләре |
| Оешмалар эшчәнлеге үзенчәлекләренә ярашлы рәвештә хезмәтне саклау таләпләрен үз эченә алган норматив хокукый актлар комплектларын формалаштыру | 2020-2022 | Эш бирүчеләр акчасы | Нурлат муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы, оешма җитәкчеләре |
| Аккредитацияләнгән оешмалар базасында оешмалар җитәкчеләре һәм баш белгечләренең хезмәтне саклау буенча укуларын оештыру | 2020-2022 | Эш бирүчеләр акчасы | Нурлат муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы, оешма җитәкчеләре |
| Турыдан-туры оешмаларда урта звено белгечләрен һәм эшче һөнәр хезмәткәрләрен хезмәтне саклау буенча укуларны оештыру | 2020-2022 | Эш бирүчеләр акчасы | Нурлат муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы, оешма җитәкчеләре |
| Махсуслаштырылган уку үзәкләрен җәлеп итеп, җитәкчеләр, белгечләр һәм эшчеләр өчен янгын куркынычсызлыгы буенча укулар оештыру һәм үткәрү (янгын сүндерү | 2020-2022 | Эш бирүчеләр акчасы | Нурлат муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы, оешма җитәкчеләре |

| | | | |
|---|---|---|---|
| буенча техник МИНИМУМ') | | | |
| «Хезмәтне саклау» айлыклары, көннәре, семинарлар, хезмәтне саклау буенча конкурслар үткәрү. | 2020<br>2021<br>2022 | Җирле бюджет:<br>30 000 сум<br>30 000 сум<br>30 000 сум | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты, Нурлат муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы, оешма җитәкчеләре |
| Предприятие һәм оешма җитәкчеләренә һәм белгечләренә хезмәтне саклау буенча гамәлдәге законнар һәм әлеге законнарны үзгәртү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итү. | 2020-2022 | Җирле бюджет | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты, Нурлат муниципаль районының хезмәтне саклау буенча Координация советы |
| Нурлат муниципаль районы сайтында һәм массакүләм мәгълүмат чаралары аша хезмәтнең торышы һәм аны саклау мәсьәләләре буенча, хезмәтне саклау өлкәсендә законнардагы үзгәрешләр турында. халыкка хәбәр итү | 2020-2022 | Җирле бюджет | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты, Нурлат муниципаль районының хезмәтне саклау буенча Координация советы |
| Хезмәткәрләрнең периодик медицина тикшерүләрен үткәрүне оештыру. | 2020-2022 | Эш бирүчеләр акчасы | Оешма җитәкчеләре |
| Нурлат муниципаль районында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауның торышын, производствода бәхетсезлек очракларының һәм һөнәри авырулар санының сәбәпләрен анализлау, аларны кисәтү буенча тәкъдимнәр эшләү. | 2020-2022 | Таләп ителми | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты, Нурлат муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы |
| Нурлат муниципаль районы оешмалары һәм предприятиеләре хезмәткәрләренең хезмәтне саклау турында хәбәрләрне кабул итү буенча «Кайнар линия» эшен оештыру. | 2020-2022 | Җирле бюджет | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты, Нурлат муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы |
| Нурлат муниципаль районы территориясендәге оешмаларда күзәтчелек органнары тарафыннан хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау торышын тикшереп торуда | 2020-2022 | Таләп ителми | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты, Нурлат муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| катнашу | | | |
| Нурлат муниципаль районы буенча хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту чаралары турында, шулай ук Нурлат муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы эшчәнлеге турында мәгълүмат әзерләү. | 2020-2022 | Таләп ителми | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты, Нурлат муниципаль районының хезмәтне саклау буенча координация советы |
| Хезмәт шартларын махсус бәяләүне оештыру һәм үткәрү. | 2020-2022 | Эш бирүчеләр акчасы | Оешма җитәкчеләре |